**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1334**
**01.03.2024**

Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы Карары белән расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары (закон актлары нигезләмәләре) үз көчен югалтуны тану турында» 2023 елның 10 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2023 елның 29 декабрендәге 2386 номерлы Карары, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 28 декабрендәге 8501 номерлы Карары белән расланган җир участокларын милеккә бушлай бирү хокукына ия затлар буларак, гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.6.1 пунктның 6 пунктчасын яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«6) гариза законлы вәкил тарафыннан бирелгән очракта, гариза бирүченең законлы вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (Россия Федерациясе Гражданнар хәле актларын теркәү органнары тарафыннан бирелгән туу турында таныклык яки Россия Федерациясе законнары нигезендә опека һәм попечительлек органнары тарафыннан бирелгән документ өлешендә) – Бердәм дәүләт гражданнар хәле актларын теркәү реестры яисә Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа (алга таба – ЕЦП), Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә һәм ЕЦП операторы билгеләгән форматлар нигезендә;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов